РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ГЛАВА САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

25.02.2019 №31-п

2019 елның апрель-июлендә хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле граждан нарга медицина тикшерүен үткәрү өчен медицина хезмәткәрләре билгеләү турында

Россия Федерациясенең “Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында”гы 1998 елның 28 мартындагы 53-ФЗ номерлы Федераль Законы, “Россия Федерациясендә гражданданнарның сәламәтлеген саклау нигезләре турында”гы 2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ номерлы Федераль Законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Хәрби-табиблык экспертизасы хакында Нигезләмәне раслау турында”гы 2013 елның 4 июлендәге 565 номерлы карары, Россия Федерациясе Оборона министрының “Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә төзелгән хәрби-табиблык комиссияләренең эшчәнлеге өчен кирәкле документлар формасын билгеләү турында” 2015 елның 14 октябрендәге 615 номерлы приказы, Россия Федерациясе Оборона министры һәм Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының “Россия Федерациясе гражданданнарын хәрби хезмәткә хәзерләүне медицина ягыннан тәэмин итүне оештыру турында”гы 2001 ел, 23 май, 240/168 нче приказы нигезендә 2019 елның апрель-июлендә хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле гражданнарга медицина тикшерүен үткәрү өчен

КАРАР БИРӘМ:

1. “Саба үзәк район хастаханәсе” дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибына 2019 елның апрель-июлендә хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле гражданнарга медицина тикшерүен үткәрү өчен тиешле санда табиб-белгечләр һәм урта медицина персоналы бүлеп бирергә тәкъдим итәргә.

2. Медицина комиссиясе үткәрүгә билгеләнгән табиб-белгечләрнең һәм урта медицина персоналының уртача айлык хезмәт хакын саклап калырга.

3. Бу карарның үтәлешенә контрольлек итүне Саба муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе М.Р. Ишниязовка йөкләргә.

Р.Н. Минниханов